**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Координационного штаба по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ

В целях обеспечения в Республике Татарстан строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов в рамках реализации национальных проектов и государственных программ **постановляю**:

1. Образовать Координационный штаб по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ.

2. Утвердить Положение о Координационном штабе по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
03 декабря 2021 года
№ УП-922

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «_03_» _декабря_ 2021 года

№ УП-_922_

**Положение**
**о Координационном штабе по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ**

1. Координационный штаб по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ (далее – Штаб) является коллегиальным совещательным консультативно-координационным органом, образованным в целях обеспечения строительства, реконструкции и капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ, организации взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти), подведомственных им учреждений, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), организаций.

2. Штаб в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Положение о Штабе и его состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

4. Штаб формируется в составе председателя Штаба, его заместителя, ответственного секретаря и членов Штаба, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

В состав Штаба включаются представители исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, правоохранительных органов, органов местного самоуправления, а также субъектов естественных монополий, ресурсоснабжающих и сетевых организаций.

5. Основными задачами Штаба являются подготовка предложений и принятие решений по вопросам:

а) организации взаимодействия и координации деятельности исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления по вопросам строительства, реконструкции и капитального ремонта объектов в рамках реализации национальных проектов и государственных программ;

б) разработки планов мероприятий, направленных на достижение целей национальных проектов и государственных программ;

в) обеспечения реализации исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, территориальными органами федеральных органов исполнительной власти, органами местного самоуправления мероприятий, направленных на достижение целей и результатов национальных проектов и государственных программ, в установленные законодательством сроки;

г) рассмотрения проблемных вопросов, связанных с угрозой срыва сроков строительства, реконструкции и капитального ремонта объектов в рамках реализации национальных проектов и государственных программ;

д) оказания методологического содействия исполнительным органам государственной власти Республики Татарстан, органам местного самоуправления по вопросам, входящим в компетенцию Штаба.

6. В соответствии с задачами Штаб имеет право:

а) запрашивать в установленном порядке у федеральных органов исполнительной власти, исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления информацию по вопросам, входящим в компетенцию Штаба;

б) приглашать на свои заседания представителей исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, организаций;

в) направлять своих представителей для участия в проводимых федеральными органами исполнительной власти, исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, иными органами и организациями совещаниях по вопросам, входящим в компетенцию Штаба;

г) привлекать к работе Штаба специалистов и экспертов в области архитектурно-строительного проектирования, инженерных изысканий и строительства объектов.

7. Председатель Штаба:

а) руководит работой Штаба;

б) принимает решение о дате, месте, времени проведения и повестке дня заседаний Штаба;

в) ведет заседания Штаба;

г) утверждает протоколы заседаний Штаба;

д) дает рекомендации членам Штаба;

е) инициирует изменение состава Штаба.

8. В период отсутствия председателя его обязанности исполняет заместитель председателя Штаба.

9. Ответственный секретарь Штаба:

а) извещает членов Штаба о дате, месте, времени проведения и повестке дня заседания Штаба, в том числе обеспечивает рассылку членам Штаба документов к заседаниям Штаба;

б) оформляет протоколы заседаний Штаба, направляет их членам Штаба;

в) готовит проекты решений Штаба, иных документов;

г) подписывает протоколы заседаний Штаба;

д) осуществляет контроль за реализацией решений, принятых Штабом;

е) осуществляет иные мероприятия по обеспечению работы Штаба.

10. Члены Штаба имеют право:

а) выступать и вносить предложения по вопросам, обсуждаемым на заседании Штаба;

б) использовать в своей деятельности информацию, полученную в рамках работы Штаба;

в) разрабатывать и вносить на обсуждение проекты решений по вопросам, входящим в компетенцию Штаба.

11. Члены Штаба принимают участие в заседании Штаба лично. В случае невозможности присутствовать на заседании Штаба по уважительной причине член Штаба заблаговременно уведомляет об этом ответственного секретаря Штаба.

12. При невозможности присутствия на заседании Штаба член Штаба вправе направить свое мнение по вопросам, включенным в повестку дня заседания Штаба, в письменной форме. Указанное мнение подлежит рассмотрению на заседании Штаба и обязательному приобщению к протоколу заседания Штаба.

13. Работа Штаба организуется в форме заседаний, совещаний членов Штаба (в том числе с использованием аудио- и видеосвязи).

14. Решения Штаба принимаются простым большинством голосов от общего количества присутствующих на заседании членов Штаба и оформляются протоколом. В протоколе указываются дата заседания, фамилии и инициалы присутствующих на нем лиц, повестка дня, результаты открытого голосования и принятые решения. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Штаба является решающим.

15. Заседания Штаба проводятся ежеквартально в рамках совещаний по вопросам строительства и реконструкции объектов инвестиционных проектов, осуществляемых в Республике Татарстан, и республиканских совещаний в режиме видеоконференции по вопросам реализации

республиканских программ капитального ремонта жилищного фонда и объектов социального назначения, программ в области модернизации жилищно-коммунального хозяйства. Внеочередные заседания Штаба могут быть инициированы председателем Штаба или членами Штаба.

16. Решения Штаба оформляются в виде протокола, который подписывается ответственным секретарем Штаба и утверждается председателем Штаба либо его заместителем.

17. Протоколы (выписки из протоколов) рассылаются ответственным секретарем Штаба членам Штаба, а также заинтересованным организациям и должностным лицам в срок, не превышающий пяти календарных дней со дня утверждения протокола заседания Штаба.

18. Ответственный секретарь Штаба осуществляет контроль за своевременным и качественным исполнением поручений, содержащихся в протоколах. В сроки, установленные председателем Штаба, ответственный секретарь Штаба представляет заместителю председателя Штаба доклады и предложения ответственных исполнителей о снятии поручений с контроля и (или) об изменении сроков исполнения поручений.

___________

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 03 » декабря 2021 года

№ УП-922

**Состав**
**Координационного штаба по обеспечению строительства, реконструкции, капитального ремонта объектов на территории Республики Татарстан в рамках реализации национальных проектов и государственных программ**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Штаба |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Штаба |
| Нигматуллин Рустам Камильевич | первый заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, ответственный секретарь Штаба |
| Аглиуллин Фаниль Анварович | министр земельных и имущественных отношений Республики Татарстан |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Гафаров Рустем Гильфанович | руководитель Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Данилов Эдуард Юрьевич | директор государственного казенного учреждения «Главное управление содержания и развития дорожно-транспортного комплекса Татарстана при Министерстве транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Загидуллин<br>Рустем Ильдусович | министр юстиции Республики Татарстан |
| Зарипов<br>Марат Ривгатович | исполнительный директор некоммерческой организации «Государственный жилищный фонд при Президенте Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Зарипова<br>Эльмира Амировна | министр труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Зяббаров<br>Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Каримов<br>Альберт Анварович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Крайнов<br>Сергей Аркадьевич | начальник Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан – главный государственный жилищный инспектор Республики Татарстан |
| Кудряшов<br>Василий Александрович | начальник Инспекции государственного строительного надзора Республики Татарстан |
| Кузюров<br>Равиль Афраимович | министр лесного хозяйства Республики Татарстан |
| Леонов<br>Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Миннахметов<br>Джаудат Мидхатович | генеральный директор государственного казенного учреждения «Главное управление инженерных сетей Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Минушев<br>Тимур Рустемович | начальник управления экономической безопасности и противодействия коррупции Министерства внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Садыков<br>Марат Наилевич | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Сибгатуллин<br>Ильдар Нурзадович | начальник управления строительства, транспорта, жилищно-коммунального и дорожного хозяйств Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Ситдиков<br>Нияз Равилевич | директор государственного казенного учреждения «Главное инвестиционно-строительное управление Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Сулейманов<br>Рифнур Хайдарович | директор акционерного общества «Татэнергосбыт» (по согласованию) |
| Сулейманов<br>Тимур Джавдетович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Файзрахманов<br>Марат Джаудатович | первый заместитель министра финансов Республики Татарстан – директор Департамента казначейства Министерства финансов Республики Татарстан |
| Хабибуллин<br>Рафис Завдатович | начальник Главного управления Министерства Российской Федерации по делам гражданской обороны, чрезвычайным ситуациям и ликвидации последствий стихийных бедствий по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хадиуллин<br>Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Хайруллин<br>Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Халиков<br>Ильдар Шафкатович | председатель Совета директоров акционерного общества «Татэнерго» (по согласованию) |
| Ханифов<br>Фарит Мударисович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Шагиахметов Мидхат Рафкатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр экономики Республики Татарстан |
| Шадриков Александр Валерьевич | министр экологии и природных ресурсов Республики Татарстан |

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы оештыру турында**

Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы оештырырга.

2. Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 03 декабрь
№ ПУ-922

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «03» декабрендәге
ПУ-922 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы турында нигезләмә**

1. Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы (алга таба – Штаб) Татарстан Республикасы территориясендә илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), алар карамагындагы учреждениеләр, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль киңәшмә консультатив координацияләү органы булып тора.

2. Штаб үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шул исәптән әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Штаб турындагы нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Штаб составына Штаб рәисе, аның урынбасары, җаваплы секретарь һәм Штабның аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы әгъзалары керә.

Штаб составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хокук саклау органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук табигый монополияләр субъектлары, ресурслар белән тәэмин итүче һәм челтәр оешмалары вәкилләре кертелә.

5. Штабның төп бурычлары булып түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм карарлар кабул итү тора:

а) илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында объектларны төзү, яңарту һәм капиталь төзекләндерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру һәм эшчәнлеген координацияләү;

б) илкүләм проектлар һәм дәүләт программалары максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чаралар планнарын эшләү;

в) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан илкүләм проектлар һәм дәүләт программаларының максатларына һәм нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән чараларны законнарда билгеләнгән вакыт эчендә гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

г) илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында объектларны төзү, яңарту һәм капиталь төзекләндерү срокларының өзелү куркынычы белән бәйле проблемалы мәсьәләләрне карау;

д) Штаб компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, җирле үзидарә органнарына методологик ярдәм күрсәтү.

6. Бурычлары нигезендә Штаб түбәндәгеләргә хокуклы:

а) федераль башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан Штаб компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга;

б) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар вәкилләрен чакырырга;

в) федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының, башка органнар һәм оешмаларның Штаб компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча уздырган киңәшмәләрендә катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

г) Штаб эшчәнлегенә архитектура-төзелеш өлкәсендә проектлау, инженерлык эзләнүләре һәм объектлар төзү өлкәсе белгечләрен һәм экспертларны җәлеп итәргә.

7. Штаб рәисе:

а) Штаб эшенә җитәкчелек итә;

б) Штаб утырышларының датасы, урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында карар кабул итә;

в) Штаб утырышын алып бара;

г) Штаб утырышлары беркетмәләрен раслый;

д) Штаб әгъзаларына күрсәтмәләр бирә;

е) Штаб составын үзгәртү мәсьәләсен күтәрә.

8. Штаб рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Штаб рәисе урынбасары башкара.

9. Штабның җаваплы секретаре:

а) Штаб әгъзаларына Штаб утырышы уздыру датасы, урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, шул исәптән Штаб әгъзаларына Штаб утырышлары документларын җибәрүне тәэмин итә;

б) Штаб утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә, аларны Штаб әгъзаларына җибәрә;

в) Штаб карарлары проектларын, башка документларны әзерли;

г) Штаб утырышы беркетмәләренә кул куя;

д) Штаб кабул иткән карарларның үтәлүен контрольдә тота;

е) Штаб эшен тәэмин итү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

10. Штаб әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Штаб утырышында тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясарга һәм тәкъдимнәр кертергә;

б) Штаб эше кысаларында алынган мәгълүматны үз эшчәнлегендә кулланырга;

в) Штаб компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча карарлар проектларын эшләргә һәм фикер алышуга кертергә.

11. Штаб әгъзалары Штаб утырышында шәхсән катнаша. Штаб утырышында җитди сәбәп аркасында катнашу мөмкин булмаган очракта, Штаб әгъзасы бу турыда алдан ук Штабның җаваплы секретарена хәбәр итә.

12. Штаб утырышында катнашу мөмкин булмаса, Штаб әгъзасы Штаб утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә җибәрергә хокуклы. Әлеге фикер Штаб утырышында каралырга һәм Штаб утырышы беркетмәсенә теркәп куелырга тиеш.

13. Штаб эше Штаб әгъзаларының утырышлары, киңәшмәләре рәвешендә оештырыла (шул исәптән аудио-һәм видеоэлемтә кулланып).

14. Штаб карарлары Штаб утырышында катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә утырыш датасы, анда катнашучы затларның фамилияләре һәм инициаллары, көн тәртибе, ачык тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Штаб утырышлары Татарстан Республикасында торак фондын һәм социаль билгеләнештәге объектларны капиталь төзекләндерү буенча республика программаларын, торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләү өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча видеоконференция режимында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектлары һәм республика киңәшмәләре кысаларында объектлар төзү һәм аларны яңарту мәсьәләләре буенча киңәшмәләре кысаларында квартал саен

үткәрелә. Штаб рәисе яки Штаб әгъзалары карары буенча Штабның чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

16. Штаб карарлары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, аңа Штаб секретаре кул куя һәм ул Штаб рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан раслана.

17. Беркетмәләр (беркетмәләрдән өземтәләр) Штаб утырышы беркетмәсе расланган көннән биш календарь көннән дә соңга калмыйча, Штабның җаваплы секретаре тарафыннан Штаб әгъзаларына, шулай ук кызыксынган оешмаларга һәм вазыйфаи затларга җибәрелә.

18. Штабның җаваплы секретаре беркетмәләрдәге йөкләмәләрнең вакытында һәм сыйфатлы үтәлүен тикшереп тора. Штаб рәисе билгеләгән срокларда Штабның җаваплы секретаре җаваплы башкаручыларның йөкләмәләрне контрольдән алу һәм (яисә) йөкләмәләрне үтәү срокларын үзгәртү турында докладларын һәм тәкъдимнәрен Штаб рәисе урынбасарына тапшыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «_03_»декабрендәге
ПУ-_922_ номерлы Указына
2 нче кушымта

**Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Штаб рәисе |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Штаб рәисе урынбасары |
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Штабның җаваплы секретаре |
| Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрын |
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Данилов Эдуард Юрьевич | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Заһидуллин<br>Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипов<br>Марат Ривгать улы | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Җәббаров<br>Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Крайнов<br>Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – Татарстан Республикасы баш дәүләт торак инспекторы |
| Кудряшов<br>Василий Александрович | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Кузюров<br>Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Миңнәхмәтов<br>Җәүдәт Мидхәт улы | «Татарстан Республикасының инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Минушев<br>Тимур Рөстәм улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сибгатуллин<br>Илдар Нурзадә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Ситдыйков<br>Нияз Равил улы | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Рифнур Хәйдәр улы | «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Хәбибуллин<br>Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Халиков<br>Илдар Шәфкать улы | «Татэнерго» акционер җәмгыяте Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |

| | |
|---|---|
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |

___